| | |
|---|---|
| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**20 март 2024 ел** **№ 3**

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылы гражданнары халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. "2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылы гражданнары халык җыенын Мортыш Баш авылы мәдәният йорты бинасында, Мортыш Баш авылы Мәктәп урамы 2 нче йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мортыш Баш торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (мотопомпа өчен запас частьләр, материаллар, күрсәткеч такта сатып алу; Мортыш Баш торак пунктындагы янгын сүндерү сулыкларына керү юлында вак таш ташу)төзү, ремонтлау);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мортыш Баш торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр; җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу);

5. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мортыш Баш торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар исемлеген төзәтү һәм яңарту; ремонт өчен материаллар сатып алу).

"ӘЙЕ" "ЮК"?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Илексаз авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Мортыш Баш авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Ф.М.Гыйлфанов

Совет Илякссазского сельского поселения
Илексаз авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001354